**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 29 июлендәге 3138 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 11 июнендәге 1465 номерлы «Совет районының Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге җир кишәрлекләренең бер өлешендә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип тану турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанда юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе гаризасын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 11 июнендәге 1465 номерлы «Совет районының Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге җир кишәрлекләренең бер өлешендә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**